**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 13** **30.12.2025**

**Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 108 номерлы «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 108 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегендә бюджет процессы турында (10.03.2015 елдан №154.2, 28.05.2018 елдан № 106, 12.11. 2019 елдан № 168, 21.07. 2021 елдан № 37, 21.06.2022 елдан № 70, 13.11.2023 елдан № 112, 28.12.2024 елның 151 номерлы үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән карарлары белән) Нигезләмәсенең 8 пунктындагы 34 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга, җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенә урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Р.Г. Нургалеев**